Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№5 (52)

Февраль, 2023 нче ел

**Татарстанда милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышланган махсус чыгарылыш**

*“Дөрес юлны табу өчен, безгә үзебезне, халыкның гүзәл йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк...”*

*Гомәр Бәширов*

Бу санда

*Музей – халык, милләт хәтере* 2
*Милли йолалар - рухи байлык* 2
*Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле* 3
*Татарның милли традицияләре* 3
*“Туган ягымда милли бәйрәмнәр” проекты* 3
*Халыклар дуслыгы* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Татарстанда гомер итүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасы зур һәм бай. Рухи хәзинәләребезне саклау һәм үстерүнең, ата-бабаларыбыздан калган милли гореф-гадәтләребезне торгызуның гаять зур әһәмияткә ия булуын исәпкә алып, шулай ук Россия халыклары мәдәни мирасы елының дәвамы буларак, 2023 елны республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итәм." – дип белдерде Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов Дәүләт Советына юлламасында.

Татарстанда «Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы» логотибы расланды. Логотип бүгенге Татарстан территориясендә гомер кичерүче төп этнографик төркемнәрнең 7 бизәгеннән төзелгән.

### Фән олимпиадалары - укучыларның гомуми белем фәннәре буенча үзенчәлекле ярышы



Фән олимпиадалары февраль аенда да дәвам итте. Куанырлык нәтиҗәләр дә бар: 4 нче а сыйныфы укучысы Мәрданова Мәрьям (укытучысы – Мортазина Л.Г.), 5 нче а сыйныфыннан Асманова Ирина (укытучысы – Ямалова Г.Ф.) татар теле фәне буенча, хокук фәненнән 9 нчы а сыйныфы укучысы Шәрипов Булат (укытучысы – Мирзаянов А.Ф.) республикакүләм олимпиада призёры булдылар. Биология фәненнән 8 нче б сыйныф укучысы Газетдинова Азалия - республикакүләм олимпиаданың йомгаклау этабы призёры һәм 10 нчы сыйныф укучысы Бариева Илина - Россиякүләм олимпиадасының регион этабы призёры (укытучылары – Бариева Л.Ф.). 7 нче б сыйныфы укучысы Садриева Рузилә республика олимпиадасының рус теле буенча йомгаклау этабының призёры (укытучысы - Фазлыева А.В.), татар мәктәпләрендә белем алучы укучылар арасында узган татар әдәбиятыннан республика олимпиасында 11 нче сыйныф укучысы Динара Шәйхиева призёр (укытучысы – Авзалова З.З.), 10 нчы сыйныф укучысы Бариева Илина (укытучысы – Бариева Л.Ф.) экология фәненнән Россиякүләм фән олимпиадасының регион этабында призер булды.

Гимназия укучылары 13 призлы урын алды, шулардан - 10 нчы сыйныф укучылары Зиннуров Илдар белән Бариева Илина икешәр призлы урын яуладылар.

Призерларны һәм аларга белем бирүче мөгаллимнәребезне чын күңелдән тәбрик итәбез!

### Минзәләдән җиңү белән…



Татарстанда милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 117 ел тулу уңаенан, Минзәлә педагогия көллияте үткәргән Муса Җәлил иҗатына багышланган "Әдәби викторина" төбәкара бәйгесендә алты команда арасында гимназиянең "Дулкыннар" командасы (җитәкчеләре: Авзалова З.З., укучылар: Сөләйманова Диана, Шәрипов Булат) беренче урынга, "Кызыл ромашка" командасы (җитәкчеләре: Солтанова Г.М., укучылар: Кашапов Данияр, Минһәҗева Камилә) икенче урынга лаек булдылар. Котлыйбыз!

# МУЗЕЙ – ХАЛЫК, МИЛЛӘТ ХӘТЕРЕ



Музей – үткәннәргә сәяхәт. Музей – халык, милләт хәтере, ул халкыбызның бай тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары, шәхесләре белән таныштыра.

Безнең Мөслим районында төбәкне өйрәнү музее бар. Анда кергәч, туган якның үткәненә сәяхәт иткәндәй буласың.

Мөслим муниципаль районы "Туган якны өйрәнү музее" директоры Нәзилә Наил кызы Бадертдинова белән очрашып, берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

***Нәзилә Наиловна, “Туган якны өйрәнү” музее нәрсә белән үзенчәлекле?***

ТР Милли музее хезмәткәрләре һәм Тарих институты галим-археологлары ярдәме белән, 2015 елның августында Мөслим төбәкне өйрәнү музееның яңа бинасы ачылды. Безнең музей Мөслим районының горурлыгына һәм брендына әйләнде.

Археология һәм табигать бүлеге бирегә килүчеләрдә аеруча зур кызыксыну уята. Музейда Этнография, Хәзерге заман тарихы (XX-XXI гасырлар) һәм сәнгать бүлекләре дә эшли. Музей коллекциясе, моннан тыш, җирле осталар агачтан, керамикадан, металлдан, шулай ук башка материаллардан ясаган үзенчәлекле эшләнмәләр исәбенә дә байый. Музейга төрле чараларга килгән кунаклар һәм катнашучылар гына түгел, мәктәп укучылары, район-



ның төрле авылларында һәм Көнчыгыш Татарстанда яшәүчеләр дә еш килә.

Күргәнебезчә, музей экспонатларга бик бай.

***Музейлар, музей дәресләре яшь буынга, укучыларга нинди тәрбия бирә? Шул турыда да әйтеп китмәссезме?***

Музейлар элек-электән яшь буынга рухи, патриотик, эстетик һәм хезмәт тәрбиясе бирү вазифасын үти. Киң карашлы, үз эшенә нык бирелгән педагоглар укучыларын музейга еш алып киләләр. Бала-

*Газетабызда кунак бар*



ларны халкыбыз тарихы, рухи казанышлары, милли үзенчәлекләре, йолалары, тормыш-көнкүрешенә кагылышлы экспонатлар белән таныштырабыз. Мондый чаралар еш кына чын мәгънәсендә тормыш дәресләренә әверелә.

***2023 ел Татарстанда милли мәдәният һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. “Туган якны өйрәнү” музеенда бу ел уңаеннан нинди чаралар планлаштырыла?***

Төрле темаларга кызыклы экскурсияләр, музей дәресләре оештыру, бәйрәмнәргә, күренекле шәхесләребезнең юбилей даталарына карата бай эчтәлекле күргәзмәләр кую, халкыбызның үткәне, гореф-гадәтләре, йола бәйрәмнәрен үткәрү күздә тотыла.

***Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт!***

***Сәхифәне***
***Солтанова Алия әзерләде***

# МИЛЛИ ЙОЛАЛАР - РУХИ БАЙЛЫК



Минем туган авылым – Мөслим. Мөслим шулай ук район үзәге дә. Искиткеч гүзәл табигате, киң асфальт урамнары, төзек, мәһабәт йортлары, милли үзаңлы, һөнәрле, тырыш, гореф-гадәтләрне саклап яшәүче халкы булуы белән күп яклардан аерылып торадыр ул. Мин үзем шундый район үзәгендә, хезмәт сөючән халкым арасында яшәвем белән бәхетле. Борынгы бабаларыбыздан мирас булып калган байлык - ул гореф-гадәтләребезне, милли йолаларыбызны бүгенге көнгә кадәр саклап калу – райондашларымның милли тәрбиялелеген күрсәтә. Шуңа да мин бик горурланам һәм милли йолаларыбыз тарихы белән кызыксынам.

Үткәнне өйрәнми торып, бүгенгене белеп булмый,” диләр бит. Шулай итеп мин милли йолалар турында тирән эчтәлекле, кызыклы мәгълүматлар туплый башладым. Вакытлы матбугат материалларына, мәктәп, район үзәк китапханәсенә һәм “Туган як” музеена, милли йолаларыбызга битараф булмый яшәүче мөхтәрәм картларчыкларга мөрәҗәгать итәм.

Кеше кайда гына яшәсә дә туган нигезен, авылының, үз халкының милли бәйрәмнәрен сагынып



кайтырлык булсын. Йолаларыбызның үзенчәлекләрен өйрәнеп, аны тагын да камилләштереп яшәү шартын максат итеп яшәсәк, үзара аралашу, очрашу-күрешү, милли дуслык, гореф-гадәтләребез беркайчан да югалмас. Кыскасы, райондашларым милли гореф-гадәтләрне хөрмәт итеп яшәр һәм яши.

***Минһаҗева Камилә,***
***10 нчы сыйныф укучысы***

## КОШ КАНАТЫ БЕЛӘН, КЕШЕ ДУСЛЫК БЕЛӘН КӨЧЛЕ

Татарстанда 2023 ел - Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Шул уңайдан гимназиядә дә эш планы булдырылды. Ел дәвамында районыбызның милли традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән тирәнрәк танышуны максат итеп алдык.

Гимназиябездә дә төрле милләт вәкилләре белем ала. Үзбәкстаннан, Кыргызстаннан, Таҗикстаннан, Казакстаннан кайтып төпләнүче кешеләрнең балалары, оныклары укый. Алар белән бергәләшеп белем хәзинәләрен туплыйбыз, сыйныфтан тыш төрле чараларда катнашабыз, мәктәп данын яклап, спорт ярышларында чыгыш ясыйбыз, кыскасы, бик дус яшибез. Төрле милли бәйрәмнәрдә катнашабыз, болар безгә физик һәм рухи яктан ныгырга мөмкинлек бирә. «Май чабу», «Нәүрүз», «Сабан туе» бәйрәмнәрендә актив катнашабыз. Аларны үзебезнең мәктәп стадионында үткәрәбез. Төрле милләт вәкилләре үзләренең җыр-биюләрен, гореф-гадәтләрен, осталыкларын күрсәтәләр.



17 февральдә Мөслим гимназиясендә башлангыч сыйныф укытучыларының регионара семинары узды. Анда "Халыкара тел көне" уңаеннан "Дуслык бәйрәме" дигән әдәби музыкаль кичә тәкъдим ителеп, төрле милләт балалары үз телләрендә шигырьләр сөйләделәр. Фатхуллина Кәримә, Фатхуллин Елмаз төрек телендә, Даллакян Давид әрмәнчә шигырьләрен яңгыратты. Гомумән, гимназиядә укучы башка милләт балалары үз телләрен дә онытмыйлар, татар телендә дә матур итеп аралашалар.

## ТАТАРНЫҢ МИЛЛИ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

### “Каз өмәсе” фестивале



Каз белән татарның тормыш юлы һәрвакыт бергә үрелеп барган. Халкыбыз тормышында каз гомер-гомергә бик дәрәҗәле, затлы кош саналган. Көзен гөрләтеп каз өмәләре уздырганнар.

Безнең Иске Вәрәш авылында 25 ноябрьдә II Бөтенроссия “Каз өмәсе” фестивале үтте.

Ул көнне авылыбыз гөрләп торды. Шулай булмыйча... Татарстанның, Рәсәйнең күп өлкәләреннән килгән кунаклар “Каз өмәсе” йолабәйрәмен карарга җыелды.

92 яшьлек Рәйсә апа Хәсәншина өенең капкалары һәркемгә ачык иде. Рәйсә апаларга каз йолкырга апалар, яшьләр җыелды. Һәркемнең үз эше: кемдер каз йолка, кемдер эчен ала, кемдер йон сыдыра, шул арада мичтә тәмле тәбикмәк пеште.

Рәйсә апа белгәннәре белән бүлеште. Йон йолкуның нинди генә уңайлы ысуллары булмасын үтүкләп йолкынганына җитми. Эч маен карда тотып суыту, бүтәкә, эчәк чистарту – һәммәсенең үз нечкәлекләре бар икән.

Йорттагы эш тәмамлангач, каз юарга чишмәгә төшү зур бәйрәм төсен алды. Иң алдан сыдырылган каурый чәчеп баручы балалар барды. Киләсе елда казларыбыз күп булсын, тормышыбыз тук булсын, дип теләү бу. Аннары өмәчеләр кузгалды. Җыр-бию, гармун тавышы тынып тормады. Чишмә буенда казларны юдылар, шул ук вакытта, тәбикмәк белән чәй эчелде, җырлар җырланды, өздереп биеп тә алдылар.

***Замалова Зәринә,***
***6 нчы в сыйныфы укучысы***

### Җиз кыңгырау моңнары



Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан Мөслимебездә икенче тапкыр «Җиз кыңгырау моңнары» фестивале үтте.

Җигүле атлар бәйрәменең төп атрибуты булды. Мәктәпләр кунакларны сыйлы табыннар белән каршы алды. Кайнар коймак, төрле чәй тәм-томнары белән сыгылып торган өстәлләрдә җылы пар чыгарып самовар кайнап утырды. Гимназиябез укучылары да бу чарада катнашып, фольклор ансамбльләр чыгышларын карадылар. Җигүле атларга утырып йөрү бәхете дә елмайды. Милли уеннарда да үзләренең тапкырлыкларын күрсәттеләр.

***Айгильдина Зарина,***
***6 нчы в сыйныфы укучысы***

## “ТУГАН ЯГЫМДА МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР” ПРОЕКТЫ









# ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

## Рухи мирас




Семык – мари халкының төп бәйрәме. Асыл мәгънәсе – мәрхүмнәрне искә алу. Семык пәнҗешәмбе көнне уздырыла. Бәйрәмгә әзерлек чәршәмбе көнне үк башлана, һәркем чистарына, мунча керә. Бу төнне кара көчләр уянып чыга дип санаганнар. Алардан саклану өчен учаклар ягылган, мылтыклардан атканнар. Ә яшьләр исә кояш баегач төрле шуклыклар эшли: морҗаны томалап китә, капка төбендәге утыннарны күрше урамга ташып өя...

Семык узасы көнне эш эшләү тыела. Бу көнне һәркем зиратка барып, мәрхүм туганнарын искә ала, өйдә алар рухына шәм яндырыла. Табын әзерләнә. Икенче көнне инде яшьләр болында күңел ача – җырлый-бии.

Кугече – Пасха атнасында дәвам итә. Догалар укыла, кышкы йокысыннан уянучы табигатькә хөрмәт белдерелә. Бәйрәмнең төп традициясе – таганнарда атыну. Мари халык риваятьләре буенча, Юмынудыр Илаһның кызы җиргә таганга утырып төшә торган булган. Көннәрдән бер көнне ул җирдә калыр өчен, таганны тотып торучы ефәк җепне очырып җибәргән һәм башка күккә күтәрелә алмаган. Алардан туган балалардан мари халкы барлыкка килгән.

***Адылова Валерия, 7 нче б сыйныфы укучысы***

*Райондагы 23 меңгә якын халыкның төп өлешен татарлар — 89,1%, руслар — 7,5%, марилар — 3,4% тәшкил итә. Райондагы 71 авыл 19 җирле үзидарә Советына берләшкән. Шуның 57се — татар, 8е — рус, 3се — рус-татар, 3 се мари авыллары.*

## Әрмән бәйрәмнәре

1700 ел христиан динен тотучы әрмәннәрнең төп бәйрәмнәре дин белән бәйле. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Иисус Христос туган көн. Ул 6 гыйнварда билгеләп үтелә. Әрмәннәр ата-бабадан калган гореф-гадәтләргә сак карый. Раштуа – гаилә бәйрәме. Мул табын артында барлык туганнар очраша. Табынның төп



сые – балык. Әрмәннәрдә ул христианлык билгесе булып санала. Кунакларны пылау белән дә сыйлыйлар. Дөге – кешелек дөньясын, ә йөзем Аллаһка якын затларны гәүдәләндерә.

Февраль аенда Бун-Барекендан – Май чабу бәйрәме. Уен-көлке, күңел ачу белән уза торган шатлыклы көн ул. Әрмән чикләвеге традициясе буенча, бу көн атабыз Адәм белән анабыз Һауваның оҗмахтагы бәхетле тормышын искә төшерә. Бу көнне ятимнәр, ярлылар, мескеннәр, авырулар игътибар үзәгендә була.

18 гыйнвар белән 23 февраль арасында әрмән халкы Изге Саркис көнен билгеләп үтә. Бәйрәм алдыннан тозлы печенье пешерелә. Аны йоклар алдыннан гына авыз итәләр. Печеньедан соң су эчәргә ярамый.

***Микаелян Артем, 4 нче а сыйныфы укучысы***

## Мин татар

Татар минем әнием дә,
Татар минем әтием.
Бабамны да татар итеп,
Сайлаган шул әбием.
Гаиләмдә һәммә кеше,
Сөйләшә туган телдә.
Ничек күңелле, рәхәт,
Яшәве Туган илдә.
Мин саклармын ахыргача,
Телемнең чисталыгын.
Мама, папа! – дип әйтмичә,
Нәселем горурлыгын.
Хөрмәтем зур урыска да,
Мари, чуваш, удмуртка.
Килештереп, телне бозып,
Калмаек без хурлыкка.

***Асылъяр Хәсәнова, 4 нче б сыйныфы укучысы***

## Идел елгасы буенда

Идел елгасы буенда,
Рәсәй дигән дәүләттә.
Урнашкан Татарстаным
Таң калдыра, әлбәттә.
Яши анда бөек халкым,
Саклап гореф - гадәтен,
Югалтмыйча ана телен,
Татарча алып белем.
Шигырьләр яза шагыйрьләр
Татарча, татлы телдә.
Җанга ягымлы яңгырый
Аларга язган көй дә.
Милли киемнәрен киеп,
Дәртле биюче парлар:
Йөзләре дә, эшләре дә
Балкып торган татарлар.
Узып китсә дә күп еллар,
Туган телем югалмас.
Таныш юлдан барыр халкым,
Ялгыш якка юл алмас.
Туган илгә мәхәббәтем -
Йөрәк түрендә минем!
Саклармын сине гомергә,
Югалтмый, туган телем!
Киләсе буынга үрнәк
Булып, яшәрбез без дә.
Калдырырбыз, сокланырлык,
Милли тарих та, эз дә.

***Минһаҗева Диләрә, 10 нчы сыйныф укучысы***

*Шигырьләр укуны дәвам итегез*

ТЫЛСЫМ+
Февраль, 2023 нче ел
№5 (52)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Минһаҗева Камилә
**Корректорлар:** Минһаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Солтанова Алия, Айгельдина Зарина
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3) **Тираж:** 100